КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 май г.Казань № 394

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган» сүзләреннән соң «ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын,» сүзләрен өстәргә;

1 нче пунктта «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган» сүзләреннән соң «ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын,» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары

проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган» сүзләреннән соң «ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын,» сүзләрен өстәргә;

1 нче пунктта «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган» сүзләреннән соң «ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын,» сүзләрен өстәргә;

2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк әһәмиятендәге объектлар урнаштыру планлаштырылуга бәйле рәвештә, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләгәндә, Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштырганда Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектлары;»;

7 нче пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясе субъектының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын» сүзләрен «Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясе субъектының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын, ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7.1 нче пункт өстәргә:

«7.1. Бу Тәртипнең 7 нче пункты нигезендә документ проектын караганда килештерүче органнар түбәндәге критерийларга таянып эш итә:

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы:

документ проектының Россия Федерациясе Президентының 2017 ел, 19 апрель, 176 нчы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экология иминлеге стратегиясенә һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2017 ел, 26 июль, б-861 нче боерыгы белән расланган 2017 – 2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасының табигый байлыклар комплексын үстерү һәм Татарстан Республикасының экология иминлеге стратегиясенә туры килү-килмәүгә карап;

документ проектының планлаштырыла торган төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштыруга карата функциональ зоналарны билгеләү һәм (яки) төбәк әһәмиятендәге линия объектларының урнашу урынын күрсәтү өлешендә Татарстан Республикасының территорияләрне планлаштыру схемасына туры килү-килмәүгә карап;

территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрен исәпкә алып;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына гамәлдәге лицензияләр нигезендә үзләштерелә торган файдалы казылмалар ятмалары урнашуын исәпкә алып;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү рискына дучар булган территорияләрне исәпкә алып;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты:

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләреннән читтә булган җирле әһәмияттәге объектларның планлаштырыла торган урнашу урынына карап;

үсемлек һәм хайван дөньясы объектларының яшәү мохитен бозуны, массакүләм авыруларын һәм корткычлары таралуны, шулай ук төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләренең хайван һәм үсемлек дөньясы объектлары һәлак булуны китереп чыгаруга сәләтле чаралар булмауга карап;

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы:

авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләрен торак пунктлары чикләренә кертүнең нигезләмәләре булу-булмауга карап;

торак пунктлары чикләренә кертүгә планлаштырыла торган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләренең махсус кыйммәтле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре исемлегендә булу-булмауга карап;

аларның санитария-саклау зоналарына авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр керә торган җирле әһәмияттәге планлаштырыла торган объектларны урнаштыру нигезләмәләре булу-булмауга карап;

торак пунктлары тирәсендәге авыл хуҗалыгы әһәмиятенә ия җирләрдә планлаштырыла торган саклык урман-болын поясларын һәм юллар буенда саклык урман үсентеләрен урнаштыру нигезләмәләре булу-булмауга карап;

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы:

муниципаль берәмлекләр чикләренең алар составындагы муниципаль районнар һәм муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен һәм аларның статусын билгеләү турындагы Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвенә карап;

торак пунктлары чикләрен алга таба кадастр исәбенә кую мөмкинлегенә карап.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Министрлык бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 3 эш көне дәвамында документ проектыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамәләрне әлеге хәбәрнамәне алган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең территорияләрне планлаштыру документы проекты «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь ТРЗ-40 нчы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба – 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга

кадәр Татарстан Республикасын Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына туры килү-килмәүне билгеләү буенча бәяләмә әзерләү һәм тәкъдимнамәләр кертү өчен Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җибәрә. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы бәяләмәсенә аның җитәкчесе (аның бәяләмәләргә кул куярга вәкаләтле урынбасары) кул куйганнан соң ул Министрлыкка җибәрелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 8.1 нче пункт өстәргә:

«8.1. Документ проектын бу Тәртипнең 8 нче пункты нигезендә караганда Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү максатларына һәм бурычларына, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен тормышка ашыру этаплары буенча күрсәткечләргә һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең озак вакытка исәпләнгән максатларына ирешүне тәэмин итә торган чаралар комплексына (шул исәптән иҗтимагый инфраструктура белән тәэмин ителү өлешендә) таянып эш итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин